СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ЯҢА ЧИШМӘ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-20-08, факс: (8-84348) 2-21-73, Nsmsp.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2024 елның 20 нче декабре № 39-148

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында» 18.11.2016 №14-48 карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә авыл җирлеге Советының 14.11.2016 №14-48 «Җир салымы турында» карарына (26.05.2017 №19-69; 31.08.2017 №21-73; 14.11.2018 № 36-115; 23.09.2019 №48-161;18.02.2021 №6-22; 19.12.2023 №32-123 карарлары редакциясендә) (алга таба - Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның беренче абзацында «җир кишәрлекләренең кадастр бәясеннән» сүзләрен төшереп калдырырга;

Карарның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яки яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә файдаланылмый торган җир кишәрлекләренә, шулай ук 2017 елның 29 июлендәге «Гражданнар тарафыннан үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә, әлеге абзацта күрсәтелгән кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән җир кишәрлекләреннән тыш;»;

Карарның 2 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак-коммуналь комплексының торак фонды һәм (яисә) инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлегеннән тыш) яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш, әлеге абзацта күрсәтелгән эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше

өчен алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән һәм һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан арткан җир кишәрлекләреннән тыш;»;

Карарның 2 пунктының бишенче абзацында «, диннәр» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пунктның сигезенче абзацында «автомобиль юллары» сүзләрен «муниципаль автомобиль юллары» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм интернет-телекоммуникация челтәрендәге Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның 1.2 һәм 1.3 пунктлары Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Яңа Чишмә авыл җирлеге Башлыгы В. М. Козлов